# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **20.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Сукаеш авыл җирлегенэ керүче Зур Сукаеш авылында
2020 елда үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш авылында халык җыены карар бирэ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Зур Сукаеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә һэм 2 Төркем инвалидлардан, 80 яшьтэн өлкәннәрдэн 150 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Зур Сукаеш авылында юлларны кардан чистарту;
- Зур Сукаеш авылында җәй көне территорияне чабу;
- Зур Сукаеш авылында Яшьләр урамы белән Бакчалы урамын тоташтырган тыкырык юлын щебенка белән чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Бэйрэм чараларын оештыру һәм уздыру өчен бүләкләр алу;
- урамнарны яктырту лампалары сатып алу һәм урнаштыру..

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Зур Сукаеш авылы, Совет ур., 30 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сукаеш авыл җирлеге башлыгы: З.Җ.Закирова